КАРАР

24 ноябрь 2021 ел № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Байлангар авылы җирлегендә Нормабаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 24.11.2021 елда түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән, гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Нормабаш авылы, Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, «I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган әниләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Нормабаш авылының Х. Такташ урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Нормабаш авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;

- Нормабаш авылының урам юл челтәрен карап тоту; (юлларны кардан чистарту, җәен авыл территориясен чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү).

- Вахитов урамы буенча урнашкан Нормабаш авылы су башнясын ремонтлау (материал сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү);

- Вахитов урамы буенча Нормабаш авылы сууткәргечен ремонтлау (материал сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү);

- Нормабаш авылында Вахит урамына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукынаия булган , җыенда катнашучылар исемлегенә,77 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 49
Тавыш бирүнә тиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 39 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

Сорау буенча карарны таныргa: «2022 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Нормабаш авылы , Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, «I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган әниләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Нормабаш авылының Х. Такташ урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Нормабаш авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;урамны яктыртуны тоту

- Нормабаш авылының урам юл челтәрен карап тоту; (юлларны кардан чистарту, җәен авыл территориясен чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, проект-смета документдарын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру).

- Нормабаш авылындагы су башняларын, суүткәргечләрне һәм артезиан скважинасын тоту; Вахитов урамы буенча урнашкан Нормабаш авылы су башнясын ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

- Нормабаш авылында Вахит урамына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3."Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирелеге башлыгы И.Ф.Каримуллин